**<u>25 нче сентябрь</u>**

**Инсценирование сказки «Бүре һәм җиде кәҗә бәтие»**

Ана телендә сөйләшергә өйрәтү, аның үзенчәлекләренә төшендерү максатыннан икенче кечкенәләр төркеме балалары белән һәркемгә билгеле һәм күпләр яраткан «Бүре һәм җиде кәҗә бәтие» әкиятенең театральләштерелгән тамашасы куелды. Рольләрне өйрәнү, тиешле киемнәр барлау, образга керү катнашучылар өчен аеруча кызыклы шөгыль булды.

